ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕЕЛГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422640, с. Большая Елга,
ул.Октябрьская, дом 25

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ ЕЛГА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422640, Олы Елга,
Октябрь урамы, 25 нче йорт,

Тел.: (84361) 25265, факс: (84361) 25265, e-mail2Belg.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2017 елның 12 июле. Олы Елга ав. № 15

Мәҗбүри эшләр рәвешендә административ
җәза бирелә торган оешмалар исемлеген
һәм мәҗбүри эш төрләрен билгеләү турында

Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тәкъдимен карап, мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза билгеләнгән затларны төзәтү, аларда нормаларга, җәмгыять кагыйдәләренә, иҗтимагый-файдалы хезмәткә карата ихтирамлы мөнәсәбәт формалаштыру максатларында, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 32.13 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Олы Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә карар бирәм:

1. Суд карарының законлы көченә кергән карары буенча административ җәза үтәү рәвешендә башкарылучы мәҗбүри эшләрнең мәҗбүри булып саналуын исәпкә алып, №1 кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге территориясендә административ җәза үтәтү өчен мәҗбүри эш төрләрен билгеләү мәҗбүри эш дип санала.

2. Мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза билгеләнгән затларның китү урыннарын булып - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре санала.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза бирелә торган оешмалар исемлеген № 2 кушымта нигезендә расларга.

4. Мәҗбүри эшләрне күрсәтелгән административ җәза билгеләнгән затларның яшәү урыны буенча башкарырга кирәк.

5. Административ җәза билгеләнгән затлар мәҗбүри эшләр башкара торган оешма җитәкчеләренә Административ хокук бозулар турында Россия

Федерациясе кодексында һәм хезмәт законнарында каралган вазыйфалар йөкләнә дип билгеләргә.

6. Суд приставларының федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Балык Бистәсе район бүлегенә административ җәза билгеләнгән затлар мәҗбүри эшләр башкара торган оешмалар администрацияләренә хокукый һәм методик ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

7. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Башкарма комитетының «мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза үтәүче оешмалар исемлеген һәм мәҗбүри эш төрләрен билгеләү турында» 2012 ел, 3 декабрь, 40 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

8. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 йорт; Казаклар авылы,Үзәк урамы, 9 йорт; Саескан Тауы авылы, Үзәк урамы, 16А йорт; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

9. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге Башлыгы Ф.Ә.Садриев

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Олы Елга авыл
җирлеге башкарма комитеты 2017
елның 12 июле, № 15
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге территориясендә административ җәза үтәтү өчен мәҗбүри эш төрләре**

1. Тышкы төзекләндерү объектларын яшелләндерү, агымдагы карап тоту һәм үстерү буенча эшләр.

2. Урамнарны җыештыру.

3. Лесосекларга бүлеп бирү (визалар кисү, делянка баганалары ясау һәм урнаштыру).

4. Урман фонды территорияләрен төзекләндерү (урман кишәрлекләрен рөхсәтсез җитештерү һәм куллану калдыкларыннан чистарту, ял итү урыннарын, беседкаларны урнаштыру).

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Олы Елга авыл
җирлеге башкарма комитеты 2017
елның 12 июле, № 15
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза бирелә торган оешмалар исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге башкарма комитеты.

2. «Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы» дәүләт бюджет учреждениесе (килешү буенча).

3. «Кама урман хуҗалыгы» дәүләт бюджет учреждениесе (килешү буенча).